ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БИЕКТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИЕКТАУ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

07.12. 2021 ел

№20

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге “Агачлар, куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газон сүтүгә рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 14 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге “Агачлар, куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газон сүтүгә рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 14 номерлы карары белән расланган агачлар, куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газон сүтүгә рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.3.1 пунктының 2 пунктчасында “агачларның, куакларның һәлакәтлелеге турында бәяләмә белән” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2.4.1. пунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.5.4. пунктын төшереп калдырырга;

1.4. 2.6.1. пунктының 4,5,7 пунктчаларында “Башкарма комитет” сүзен “Башкарма комитет яисә төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы” сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.1. пунктының 6,11 пунктчаларында “Башкарма комитет” сүзен “Башкарма комитет яисә төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы” сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 2.6.3. пунктында “Башкарма комитетның структур бүлекчәсе” сүзләрен “муниципаль районның җирле үзидарә органнары, Башкарма комитет”сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 2.8.2 пунктының 2 пунктчасында “гаризада күрсәтелгән яшел утыртмаларны тикшерү нәтиҗәсендә яшел утыртмаларны (авария хәлендәге агачларны) сүтүнең зарурлыгы расланмау” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 2.8.2 пунктының 5 пунктчасында “(авария-торгызу эшләрен башкару белән бәйле яисә яшел утыртмаларны җимерү өчен бик кирәк очраклардан тыш (агачның, авария хәлендәге агачларның аву куркынычын бетерү өчен)” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9. 2.8.4 пунктында “2 нче кушымтада” сүзләрен “3 нче кушымтада” сүзләренә алмаштырырга;

1.10. 3.4.2 пунктының дүртенче абзацында “,шулай ук авария-торгызу эшләрен уздыру өчен яшел утыртмаларны кисүгә яисә яшел утыртмаларны җимерү өчен аеруча зарурлык булган хәлдә (агачның, авария хәлендәге агачларның аву куркынычын бетерү өчен) рөхсәтнамә алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта)” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.11. 3.5.2.3. пунктын төшереп калдырырга;

1.12. 3.5.5. пунктында “;авария-торгызу эшләрен уздырганда яисә яшел утыртмаларны җимерү өчен аеруча зарурлык булган хәлдә (агачның, авария хәлендәге агачларның аву куркынычын бетерү өчен) гариза бирүче муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта – ике эш көне” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.13. Регламентка 2 нче кушымтада “Авария хәлендәге агачлар кыска вакыт эчендә киселергә тиеш.” сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Биектау авылы, Х. Сафиуллин урамы, 4 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Околоток-Яңасала авылы, Калинин урамы, 102 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Чаллыбаш авылы, М. Горький урамы, 69 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге вазыйфаларын башкаручы А.Р.Гилазиева